ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 август 2018 ел № 4822

Башкарма комитетның 2016 елның 1 ноябрендәге
5731 нче карары белән расланган 2017-2019 елларга
Яр Чаллы шәһәрендә мәдәният үсешенең муниципаль
программасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 1 ноябрендәге 5731 нче карары белән расланган (Башкарма комитетның 2017 елның 13 сентябрендәге 5406 нчы, 2017 елның 5 декабрендәге 7541 нче, 2018 елның 12 мартындагы 1244 нче, 2018 елның 23 маендагы 2889 нчы карарлары редакциясендә) 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәният үсешенең муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Тармакның кадрлар потенциалын үстерү, тармакта эшләү һәм иҗади эшчәнлек өчен стимуллаштыру шартларын булдыру» ярдәмче программасының 8 бүлегенә:

- «Ярдәмче программаны финанслауның күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Финанслау структурасы

мең сум

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслау күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге | 3986,1 | 1369,1 | 1247,9 | 1397,9 |
| Барлыгы | 3986,1 | 1369,1 | 1247,9 | 1397,9 |

- «Шәһәр һөнәри осталык конкурслары үткәрү» пунктындагы «2018» баганасында «157,2» санын «0,0» санына алмаштырырга;

- «Ярдәмче программа буенча барлыгы – 6, шул исәптән» дигән юлдагы «Ярдәмче программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, чаралары һәм финанслау» бүлегендә «2018» баганасында «1405,1» санын «1247,9» санына алмаштырырга.

2) 2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның мәдәниятен саклау һәм үстерү» ярдәмче программасының 8 бүлегендә:

- «Ярдәмче программаны финанслауның күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Финанслау структурасы мең сум

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслау күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге | 3965,6 | 1275,6 | 1440,0 | 1250,0 |
| Барлыгы | 3965,6 | 1275,6 | 1440,0 | 1250,0 |

- «Ярдәмче программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, чаралары һәм финанслау» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның билгеләнеше | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау (мең сум) | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2016 (базовый) | 2017 | 2018 | 2019 | 2017 | 2018 | 2019 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Максат: Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләрнең мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм яңа ихтыяҗларын формалаштыру, Яр Чаллы шәһәренең мәдәни потенциалын саклау һәм үстерү | | | | | | | | | | | |
| 1 нче бурыч. Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятләрен саклау һәм үстерү, мәдәни, халыкара бәйләнешләрне үстерү | | | | | | | | | | | |
| Шәһәр конкурслары, фестивальләр, күргәзмәләр, календарь бәйрәмнәр үткәрү, республика, бөтенроссия конкурслары, фестивальләре һәм күргәзмәләрендә катнашу | Мәдәният идарәсе, муниципаль мәдәният учреждениеләре, Башкарма комитетның район Хакимиятләре | 2017-2019 еллар | Үткәрелгән бәйрәмнәр, милли мәдәният көннәренең саны (ким булмаган), берәмлеге | 6 | 6 | 6 | 6 | 966,2 | 848,9 | 550,0 | Шәһәрдә яшәүчеләрне фольклор чараларда катнашуга стимуллаштыру. Үзешчән коллективларның, аерым башкаручыларның, рәссамнарның иҗатын стимуллаштыру, аларның иҗатын популярлаштыру |
| Коллективлар өчен сәхнә костюмнары сатып алу | Мәдәният идарәсе, муниципаль мәдәният учреждениеләре | 2017-2019 еллар | Коллективлар саны (ким булмаган), берәмлеге | 1 | 1 | 1 | 1 | 0,0 | 245,0 | 200,0 | Коллективларның үсеше өчен шартлар тудыру |
| Музыка уен | Мәдәният | 2017- | Исемнәрнең | 1 | 1 | 1 | 1 | 199,4 | 222,1 | 300,0 | Коллективла |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| кораллары һәм сәхнә җиһазлары сатып алу | идарәсе, муниципаль мәдәният учреждениеләре | 2019 еллар | саны (ким булмаган), берәмлеге | | | | | | | рның үсеше өчен шартлар тудыру |
| 2 нче бурыч. Нәшир итү эшен үстерү | | | | | | | | | | |
| Китаплар, басма продукцияне бастырып чыгару һәм сатып алу | Мәдәният идарәсе, муниципаль мәдәният учреждениеләре | 2017-2019 еллар | Басма продукция исемнәренең саны (ким булмаган), берәмлеге | 1 | 1 | 1 | 1 | 60,0 | 74,0 | 150,0 | Шәһәрнең тарихи-мәдәни мирасын саклау, Чаллы язучыларының иҗатын популярлаштыру |
| 3 нче бурыч. Китапханәләр эшен үстерү | | | | | | | | | | |
| Татар һәм рус прозасын һәм поэзиясен популярлаштыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрү | Мәдәният идарәсе, «Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУ | 2017-2019 еллар | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлеге | 3 | 3 | 3 | 3 | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Матур әдәбият әсәрләрен популярлаштыру |
| Ярдәмче программа буенча барлыгы - 7, шул исәптән | | | | | | | | 1275,6 | 1440,0 | 1250,0 | |

3) «2017-2019 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасының 8 бүлегендә:

- «Төп чараларның исеме» баганасындагы «Музей коллекцияләрен тулыландыру, музей эшен популярлаштыру» дигән юлны «Музей коллекцияләрен тулыландыру, музей эшен модернизацияләү һәм популярлаштыру» га алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин